ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

23.05.2025 г. Заинск № 255

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 6 сентябрендәге 488 номерлы «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы милкендәге һәм мондый мөлкәтне сатып алуга өстенлекле хокукны гамәлгә ашырганда кече һәм урта эшкуарлык субъектлары тарафыннан сатып алына торган арендалана торган күчемле һәм күчемсез мөлкәт өчен түләүне кичектереп түләү срогын билгеләү турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы һәм «Дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектлары тарафыннан арендалана торган күчемсез мөлкәтне читләштерү үзенчәлекләре турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» федераль законнар нигезендә, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләр Советы тәкъдимнәрен үтәү йөзеннән Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 6 сентябрендәге 488 номерлы «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы милкендәге һәм мондый мөлкәтне сатып алуга өстенлекле хокукны гамәлгә ашырганда кече һәм урта эшкуарлык субъектлары тарафыннан сатып алына торган арендалана торган күчемле һәм күчемсез мөлкәткә түләүне кичектереп түләү срогын билгеләү турында» карарының 1 пунктына, аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы милкендәге һәм мондый мөлкәтне сатып алуга өстенлекле хокукны гамәлгә ашырганда кече һәм урта эшкуарлык субъектлары тарафыннан сатып алына торган арендалана торган мөлкәт өчен түләүне кичектереп түләү срогы күчемсез мөлкәт өчен 8 (сигез) ел һәм күчемле мөлкәт өчен 3 (өч) ел тәшкил итә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (prav.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2025елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисадый үсеш, сәнәгать, сәүдә һәм эшкуарлыкка ярдәм буенча урынбасары М. М. Хәбибуллинга йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Э.Э. Галеев**